СОВЕТ КАТМЫШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Кирова, д.74, с. Катмыш,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422177

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КАТМЫШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Киров ур., 74 нче йорт, Катмыш авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422177

тел.(факс): (85563) 4-05-21; e-mail:Katmish.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение Карар
«18» июля 2023г. №1-27

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлыФедераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегеУставын гамәлдәге законнарга туры китерү максатында, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге Советының 2018 елның 18 июнендәге 1-34 номерлы карары белән кабул ителгән «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегеУставына кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.

2.Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә җибәрергә.

3. Әлеге карарны, дәүләт теркәвенә алынганнан соң, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясындагы 8 өлеше, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 89 статьясының 2 өлеше нигезләмәләрен исәпкә алып, рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлеше буенча җаваплылыкны Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге башлыгы вазыйфаларын башкаручы Р.Р.Габделбәровка йөкләргә.

Катмыш авыл җирлеге
башлыгы вазыйфаларын бшкаручы /Р.Р.Габделбәров/

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Катмыш авыл җирлеге Советының
18 июль 2023 ел, №1-27
карарына 1 нче кушымта

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы
Катмыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына кертелә торган
үзгәрешләр

1. 19 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«« Авыл торак пунктының Старостосы составына әлеге торак пункт кергән җирлек Советы тарафыннан авыл торак пунктындагы гражданнар җыены тәкъдиме буенча билгеләнә. Авыл торак пунктының Старостасы итеп әлеге авыл торак пункты территориясендә яшәүче һәм актив сайлау хокукына ия Россия Федерациясе гражданнары, йә тәкъдим ителгән көнгә 18 яшькә җиткән һәм шушы авыл торак пункты территориясендә урнашкан торак урыны булган Россия Федерациясе гражданнары арасыннан билгеләнә.»;

2. 19 статьяның 3 өлешендә «муниципаль вазыйфа» сүзләреннән соң «, үз вәкаләтләрен даими нигездә башкармый торган Җирлек Советы депутаты муниципаль вазыйфасыннан тыш,» сүзләрен өстәргә;»;

3. 19 статьяның 4 өлешендәге 1 пунктында «муниципаль вазыйфа» сүзләреннәнсоң «, үз вәкаләтләрен даими нигездә башкармыйторган Җирлек Советы депутаты муниципаль вазыйфасыннан тыш,» сүзләренөстәргә;»;

4. 31 статьяның 11 өлешендә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

5. 31 статьяның 12 өлешендә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренәалмаштырырга;

6. 31 статьяның 13 өлешенүзкөченюгалткандиптанырга;

7. 41 статьяның 5 өлешендә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;»;

8. 43статьяның 1 өлешендә Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;»;

9. 41 статьягатүбәндәгередакциядәге 1.1 өлешөстәргә:

«1.1. Җирлек Советы депутаты нигезлесәбәпләрбулмагандаалты ай дәвамында Җирлек Советыныңбарлыкутырышларындабулмаганочракта, Җирлек Советы карары белән вакытыннан алда туктатыла.»;

10. 10. 44 статьяның 5 өлешендәге 12 пунктының 6 абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;
11. 46 статьяның 8 өлешендәге 12 пунктындагы 6 абзацта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;
12. 47 статьяның 4 өлешендә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен« Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

13. 47 статьяның 1 өлешендәге 9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"9) Россия Федерациясе гражданлыгын яисәчит ил гражданына җирле үзидарә органнарына сайлану хокукын бирә торган Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә катнашучы чит ил гражданлыгын туктаткан, чит ил гражданына Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе нигезендә җирле үзидарә органнарына сайланырга хокук бирә торган, яисә Россия Федерациясе гражданына чит ил территориясендә даими яшәү хокукын раслаучы башка документ булган, чит ил гражданлыгы (подданлыгы) булган, яшәүгә рөхсәткә ия булган очракта, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе нигезендә башкасы каралмаган булса;»;
14. 80 статьяның 7 өлешендәге 3 абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;